РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
21.04.2021

КАРАР
№ 443-п

Торак урыны мәйданының исәп-хисап нормасы
һәм социаль наем шартнамәсе буенча
торак урыны мәйданын бирү нормасы турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьяларын тормышка ашыру, дәүләт торак программаларын тормышка ашыру максатыннан, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында, гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында, торак урыны мәйданының гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсе гаиләнең бер әгъзасына торак урынының 18 кв.метрдан да ким булмаган гомуми мәйданы күләмендә билгеләнә торган торак урыны мәйданының исәп нормасын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында, социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннары белән тәэмин ителешнең ирешелгән дәрәҗәсеннән чыгып, 1 гражданинга торак урынының 18 кв.метрдан да ким булмаган гомуми мәйданы күләмендә социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданын бирү нормасын билгеләргә.

3. Торак урынының гомуми мәйданын бирү нормасын арттыру Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда рөхсәт ителә.

4. Түбәндәге карарларны үз көчләрен югалткан дип танырга:

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Исәпкә куйганда һәм социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак биргәндә торак мәйданы нормалары турында” 2006 елның 30 июнендәге 363-п номерлы карары;

– “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең “Исәпкә куйганда һәм социаль наем һәм дәүләт торак программалары буенча гражданнарга торак биргәндә торак мәйданы нормалары турында” 2006 елның 30 июнендәге 363-п номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2007 елның 4 сентябрендәге 398-п номерлы карары;

5. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын
башкаручы, Башкарма комитет Җитәкчесенең
икътисад буенча урынбасары –
икътисад бүлеге башлыгы М.М. Багманов